**Практик эш. 8 нче сыйныф (рус төркеме), 4 чирек. Без спорт яратабыз.**

**1.Прочитайте текст. Текстны укыгыз.**

**Без спорт яратабыз**

Кайбер кешеләр беркайчан да спорт белән шөгыльләнмиләр. Кеше организмы өчен зыянлы әйберләр кулланучылар да күп. Кайберәүләр күп ашыйлар. Андый кешеләр еш авырыйлар.

Без гаиләбез белән спорт яратабыз. **Минем әтием белән энем һәр көнне 5 чакрым араны йөгерәләр.** Аларның сәламәтлекләре нык. Минем әтием спиртлы эчемлекләр эчми, тәмәке тартмый. Мин әнием белән ял көннәрендә аэробикага йөрим. Һәр көнне иртән җиләк - җимеш ашыйбыз. Яшелчәләрнең дә файдасы зур. Мин шикәр ашамыйм. Ул тешләргә зыянлы.

Минем энем йөзәргә ярата, велосипедта йөри. Йөзү умырткалыкка файдалы. Велосипедта йөрү мускулларны ныгыта. Энем йога белән дә кызыксына. **Йога дөрес сулыш алырга өйрәтә, нерв системасын тынычландыра.**

Ябыгу өчен, йөгерү файдалы. Ул йөрәк эшчәнле-генә дә, сулыш алу органнарына да уңай йогынты ясый. Миңа теннис бик ошый. Аның аяклар һәм куллар өчен файдасы бик зур.

**2.Выберите правильный ответ. Дөрес җавапны билгеләгез. (5б.)**

1. Кеше организмы өчен зыянлы әйберләр кулланучылар бик аз.
   1)текстка туры килә 2)текстка туры килми
2. Әтием белән энем һәр көнне 10 чакрым араны йөгерәләр
   1)текстка туры килә 2)текстка туры килми
3. Мин аэробикага әнием белән йөрим.
   1)текстка туры килә 2)текстка туры килми
4. Йога дөрес сулыш алырга өйрәтә, нерв системасын тынычландыра.
   1) текстка туры килә 2)текстка туры килми
5. Мин теннис уйнарга яратмыйм.
   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**3. Допишите предложения. Җөмләләрне язып бетерегез. (6б.)**

Мин спорт яратам, чөнки..... Без гаиләбез белән спортзалга йөрибез, ...... Яшелчәләрне күп ашарга кирәк, чөнки..... Энем йога белән кызыксына, ә мин.... Йөгерү бик файдалы, шуңа күрә....

**4.Составьте предложения по данным словам. Әлеге сүзләр белән җөмләләр төзегез.(6б.)**

Спорт, кеше,яраткан,бәхетле,бик. Минем, волейбол, ярата, сыйныфташым. Йөгерү, файдалы, бик, шуңа күрә, көн саен, гаиләбез белән,без,йөгерәбез. Сәламәтлекне, сакларга, чөнки, зур,ул,байлык,кирәк. Һәр,көнне, ашарга,кирәк,җиләк-җимеш, иртән.

**5.Напишите по 2 вопроса к выделенным предложениям. Җөмләләргә сораулар төзегез. (8б.)**

**6.Составьте план текста. Текстның планын төзегез. (6б.)**

**Практик эш. 7 нче сыйныф (рус төркеме), 4 чирек. Җәйне көтәбез.**

**1.Прочитайте текст. Текстны укыгыз.**

Бу хәл күп еллар элек булды. Без ул вакытта авылда тора идек. Җәйге эссе көн. **Авылның бөтен кешесе болында печән чаба.** Минем абый да шунда китте. Өч сәгатьтән ул ашарга кайтты. Карыйм, күлмәк эчендә нидер бар. Ул керпе булып чыкты.

Шул көннән керпе бездә тора башлады. Башта аңа авыр булды. Ул өстәл астына да, карават астына да кереп кача иде. Аннан соң ул безнең янга да чыга башлады. **Без аңа иртән һәм кичен — сөт, ә көндез ит бирәбез.** Кич белән барыбыз да йокларга ятабыз. Керпе генә йокламый. Ул тычканнар тота.

Салкын буранлы кыш җитте. Аның артыннан матур яз килде. Керпе һаман бездә яшәде. Җәйге көннәрнең берсендә без аны ишегалдына чыгардык. Шуннан соң без аны күрмәдек, ул югалды. Үзенең болынына киткәндер инде.

***(«Ялкын» журналыннан)***

**2.Выберите правильный ответ. Дөрес җавапны билгеләгез. (5б.)**

1. Бу хәл күз көне булды.
   1)текстка туры килә 2)текстка туры килми
2. Күлмәк эчендә керпе булып чыкты.
   1)текстка туры килә 2)текстка туры килми
3. Без аңа иртән һәм кичен — сөт, ә көндез ит бирәбез

   1)текстка туры килә 2)текстка туры килми
4. Кышкы көннәрнең берсендә без аны ишегалдына чыгардык.
   1) текстка туры килә 2)текстка туры килми
5. Керпе үзенең болынына киткәндер.

   1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**3. Допишите предложения. Җөмләләрне язып бетерегез. (6б.)**

Мин җәйне яратам, чөнки..... Без гаиләбез белән җәйге каникулларда ...... Мин лагерьга барырга яратам, ә дустым .... Җәй көне табигать бик матур, шуңа күрә ....

**4.Составьте предложения по данным словам. Әлеге сүзләр белән җөмләләр төзегез.(6б.)**

Җәй,бакчада,көне,күп,эш. Җәй,көне, җиләк-җимеш, өлгерә, яшелчәләр. Җәйге, авылда,рәхәт,каникулларда, күңелле. Без, йөзәбез, кызынабыз, чәчәкләр,матур, җиләкләр, тәмле, җыябыз.

**5.Напишите по 2 вопроса к выделенным предложениям. Җөмләләргә сораулар төзегез. (8б.)**

**6.Составьте план текста. Текстның планын төзегез. (6б.)**

**Баллар**
**31-27 =5**
**26-20=4**
**19-13=3**
**12-0=2**